ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 март, 2025 ел № 43/9

Шәһәр Советының аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, ««Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/10 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8, 2024 елның 6 декабрендәге 39/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 28 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«28. Профилактик визит инспектор тарафыннан контрольдәге затның эш урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдәге зат эшчәнлегенә яки аңа караган контроль объектларына карата мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч критерийларына туры килүе, куркыныч категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, төрләре, эчтәлеге һәм контроль объектына карата аны тиешле куркыныч категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр ителә, инспектор контроль объекты белән танышуны, контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыюны тормышка ашыра һәм контрольдәге затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит Контроль орган (мәҗбүри профилактик визит) яки контрольдәге зат инициативасы белән үткәрелә.

Профилактик визит үткәрү йомгаклары буенча контроль объектына мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен гавами бәяләү бирелергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 29.1 пункт белән тулыландырырга:

Мәҗбүри профилактик визит контрольдәге затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында инспектор, кирәк булганда, карап тикшерү, кирәкле документларны сорап алу, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза үткәрә.

Мәҗбүри профилактик визит уздыру срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.

Мәҗбүри профилактик визит тәмамланганнан соң мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт төзелә. Контрольдәге зат яки аның вәкиле мәҗбүри профилактик визит актының эчтәлеге белән Федераль законның 88 статьясында каралган тәртиптә таныша.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкин булмаган очракта, Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча контрольдәге затка карата мәҗбүри профилактик визитны кабат үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә, әгәр мондый хокук бозулар Федераль законда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри профилактик визит уздыру тәмамланганчы бетерелмәгән булса, контрольдәге затка бирелә.»;

3) 30-33 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

30. Әгәр контрольдәге зат кече эшмәкәрлек субъектларына караса, социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешма, дәүләт яки муниципаль учреждение булса, контрольдәге зат инициативасы белән профилактик визит аның гаризасы нигезендә үткәрелергә мөмкин.

31. Контрольдәге зат профилактик визит уздыру турында гаризаны бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирә.

Контроль орган гаризаны 10 эш көнендә карый һәм профилактик визит үткәрү яки аны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдәге затка хәбәр бирә.

Профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, аны үткәрү датасын Контроль орган контрольдәге зат белән килештерүне теркәүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән 20 эш көнендә килештерә.

32. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) контрольдәге заттан гаризасын кире алу турында хәбәр килгәндә;

2) кабат гариза бирү датасына кадәр алты ай эчендә контрольдәге затның профилактик визит уздыру урынында булмавы яки аның профилактик визит уздырырга мөмкинлек бирмәгән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә;

3) гариза биргән көнгә кадәр бер ел эчендә элек бирелгән гариза буенча Контроль орган тарафыннан профилактик визит үткәрелгәндә;

4) гаризада цензурасыз яки мыскыллаучы сүзләр, Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булганда.

Профилактик визит уздырудан баш тарту турындагы карарга контрольдәге зат тарафыннан шикаять бирелергә мөмкин.

Контрольдәге зат гаризасын кире алырга яки профилактик визит уздырудан баш тартырга хокуклы, бу хакта контроль органына аны уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

33. Профилактик визит кысаларында контрольдәге затның ризалыгы белән инспектор пробалар (үрнәкләр) сайлап ала, инструменталь тикшерү, сынау үткәрә.

4) түбәндәге эчтәлектәге 33.1.-33.3. пунктлар белән тулыландырырга:

«33.1. Контрольдәге затларга профилактик визит барышында бирелгән аңлатмалар һәм тәкъдимнәр рекомендация характерына ия.

33.2. Профилактик визит үткәргәндә контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы яисә мондый зыян (зарар) китерелүе ачыкланган очракта, инспектор контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затына кичекмәстән мәгълүмат җибәрә.

33.3. Контроль орган үткәрелгән профилактик визитлар хисабын алып бара.»;

5) 34 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Инспекция визиты, күчмә тикшерү дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

6) 36 пунктта:

- 1, 3 пунктчаларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Федераль законның 60 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, Контроль органда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү турында яисә зыян (зарар) китерү куркынычы хакында белешмәләр булу;

3) контрольдәге конкрет затларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе (шул исәптән гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә карата);»;

- түбәндәге эчтәлектәге 6,7 пунктчалар өстәргә:

«6) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау;

7) контрольдәге затның мәҗбүри профилактик визит уздырудан качарга тырышуы.»;

7 39 пунктның икенче абзацында «Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне, күчмә тикшерүне» сүзләрен «Контрольдәге затлар белән үзара бәйләнешсез контроль чаралар» сүзләренә алыштырырга;

8) 89 пунктның икенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

9) 111 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«111. Шикаять судка кадәрге шикаятьнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә Контроль орган тарафыннан каралырга тиеш.

Контрольдәге затның тикшерү объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.».

2. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын башкаруга муниципаль контроль турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2024 елның 6 декабрендәге 39/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 36 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Инспекция визиты дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»

2) 40 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Рейд күзәтүе дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

3) 46 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин»;

4) 54 пунктның беренче абзацында «гамәлләрне кылырга» сүзләрен «үткәрелергә» дип үзгәртергә;

5) 57 пунктны көчен югалткан дип танырга;

6) 86 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«86. Шикаять судка кадәрге шикаятьнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә Контроль орган тарафыннан каралырга тиеш.

Контрольдәге затның тикшерү объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.».

3. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/12 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8, 2024 елның 6 декабрендәге 39/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 25 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«25. Профилактик визит инспектор тарафыннан контрольдәге затның эш урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдәге зат эшчәнлегенә яки аңа караган контроль объектларына карата мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч критерийларына туры килүе, куркыныч категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, төрләре, эчтәлеге һәм контроль объектына карата аны тиешле куркыныч категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр ителә, ә инспектор контроль объекты белән танышуны, контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыюны тормышка ашыра һәм контрольдәге затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит Контроль орган яки контрольдәге зат инициативасы белән үткәрелә.

Профилактик визит үткәрү йомгаклары буенча контроль объектына мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен гавами бәяләү бирелергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 26.1 пункт белән тулыландырырга:

«26.1. Мәҗбүри профилактик визит контрольдәге затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында инспектор кирәк булганда карап тикшерү, кирәкле документларны сорап алу, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза үткәрә.

Мәҗбүри профилактик визит уздыру срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.

Мәҗбүри профилактик визит тәмамланганнан соң мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт төзелә.

Контрольдәге зат яки аның вәкиле мәҗбүри профилактик визит актының эчтәлеге белән 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясында каралган тәртиптә таныша.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкин булмаган очракта, Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән алып, өч айдан да соңга калмыйча, контрольдәге затка карата мәҗбүри профилактик визитны кабат үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә, әгәр мондый хокук бозулар Федераль законда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри профилактик визит уздыру тәмамланганчы бетерелмәгән булса, контрольдәге затка бирелә.»;

3) 27-30 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

27. Әгәр контрольдәге зат кече эшмәкәрлек субъектларына караса, социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешма, дәүләт яки муниципаль учреждение булса, контрольдәге зат инициативасы белән профилактик визит аның гаризасы нигезендә үткәрелергә мөмкин.

28. Контрольдәге зат профилактик визит уздыру турында гаризаны бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирә.

Контроль орган гаризаны 10 эш көнендә карый һәм профилактик визит үткәрү яки аны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдәге затка хәбәр бирә.

Профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, аны үткәрү датасын Контроль орган контрольдәге зат белән килештерүне теркәүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән 20 эш көнендә килештерә.

29. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) контрольдәге заттан гаризасын кире алу турында хәбәр килгәндә;

2) кабат гариза бирү датасына кадәр алты ай эчендә контрольдәге затның профилактик визит уздыру урынында булмавы яки аның профилактик визит уздырырга мөмкинлек бирмәгән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә;

3) гариза биргән көнгә кадәр бер ел эчендә элек бирелгән гариза буенча Контроль орган тарафыннан профилактик визит үткәрелгәндә;

4) гаризада цензурасыз яки мыскыллаучы сүзләр, Контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булганда.

Профилактик визит уздырудан баш тарту турындагы карарга контрольдәге зат тарафыннан шикаять бирелергә мөмкин.

Контрольдәге зат гаризасын кире алырга яки профилактик визит уздырудан баш тартырга хокуклы, бу хакта контроль органына аны уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

30. Профилактик визит кысаларында контрольдәге затның ризалыгы белән инспектор пробалар (үрнәкләр) сайлап ала, инструменталь тикшерү, сынау үткәрә. »;

4) түбәндәге эчтәлектәге 30.1.-30.3. пунктчалар белән тулыландырырга:

«30.1. Контрольдәге затларга профилактик визит барышында бирелгән аңлатмалар һәм тәкъдимнәр рекомендация характерына ия.

30.2. Профилактик визит үткәргәндә контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы яисә мондый зыян (зарар) китерелүе ачыкланган очракта, инспектор контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затына кичекмәстән мәгълүмат җибәрә.

30.3. Контроль орган үткәрелгән профилактик визитлар хисабын алып бара.»;

5) 31 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Инспекция визиты, күчмә тикшерү, рейд күзәтүе дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

6) 33 пунктта:

- 1, 3 пунктчаларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Федераль законның 60 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, Контроль органда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү турында яисә зыян (зарар) китерү куркынычы хакында белешмәләр булу;

3) контрольдәге конкрет затларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе (шул исәптән гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә карата);»;

- түбәндәге эчтәлектәге 6,7 пунктчалар өстәргә:

«6) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау;

7) контрольдәге затның мәҗбүри профилактик визит уздырудан качарга тырышуы.»;

7) 35 пунктның икенче абзацында «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга барып тикшерү» сүзләрен «үзара бәйләнешсез контроль чаралар» сүзләренә алыштырырга;

8) 65 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«65. Планнан тыш документар тикшерү, аны уздыруның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктларында каралган очракларыннан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килештереп үткәрелергә мөмкин.»;

9) 81 пунктта алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инспекция визиты дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

10) 82 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«65. Планнан тыш инспекция визиты, аны уздыруның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктларында, 3 өлешендә, 66 статьясындагы 12 өлешендә каралган очракларыннан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килештереп үткәрелергә мөмкин.»;

11) 87 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«87. Рейд күзәтүе, аны уздыруның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктларында, 3 өлешендә, 66 статьясындагы 12 өлешендә каралган очракларыннан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килештереп үткәрелергә мөмкин.»;

12) 92 пунктта икенче абзацта «гамәлләрне кылырга» сүзләрен «үткәрелергә» дип үзгәртергә;

13) 93 пунктның икенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

14) 94 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«94. Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча, контроль төре турында Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, әлеге Нигезләмәнең 41 пунктындагы 2 пунктчасында каралган карар кабул ителә алмый.»

15) 116 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«116. Шикаять судка кадәрге шикаятьнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә Контроль орган тарафыннан каралырга тиеш.

Контрольдәге затның тикшерү объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.».

4. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8, 2024 елның 6 декабрендәге 39/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 32 пунктның беренче һәм икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«32. Профилактик визит инспектор тарафыннан контрольдәге затның эш урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдәге зат эшчәнлегенә яки аңа караган контроль объектларына карата мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч критерийларына туры килүе, куркыныч категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, төрләре, эчтәлеге һәм контроль объектына карата аны тиешле куркыныч категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр ителә, инспектор контроль объекты белән танышуны, контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыюны тормышка ашыра һәм контрольдәге затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.»;

2) 33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Мәҗбүри профилактик визит җир законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыруга керешкән контрольдәге затларга карата мондый эшчәнлек башланганнан соң бер ел эчендә үткәрелә.

Мәҗбүри профилактик визит контрольдәге затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында инспектор кирәк булганда карап тикшерү, кирәкле документларны сорап алу, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза үткәрә.

Мәҗбүри профилактик визит уздыру срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.

Мәҗбүри профилактик визит тәмамланганнан соң мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт төзелә.

Контрольдәге зат яки аның вәкиле мәҗбүри профилактик визит актының эчтәлеге белән 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясында каралган тәртиптә таныша.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкин булмаган очракта, контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча контрольдәге затка карата мәҗбүри профилактик визитны кабат үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә, әгәр мондый хокук бозулар мәҗбүри профилактик визит тәмамланганчы бетерелмәгән булса, контрольдәге затка бирелә.

3) түбәндәге эчтәлектәге 33.1. - 33.6. пунктлар белән тулыландырырга:

«33.1. Әгәр контрольдәге зат кече эшмәкәрлек субъектларына караса, социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешма, дәүләт яки муниципаль учреждение булса, контрольдәге зат инициативасы белән профилактик визит аның гаризасы нигезендә үткәрелергә мөмкин.

Контрольдәге зат профилактик визит уздыру турында гаризаны бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирә.

Контроль орган гаризаны 10эш көнендә карый һәм профилактик визит үткәрү яки аны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдәге затка хәбәр итә.

Профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, аны үткәрү датасын Контроль орган контрольдәге зат белән килештерүне теркәүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән 20 эш көнендә килештерә.

33.2. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Контрольдәге заттан гаризасын кире алу турында хәбәр килгәндә;

2) кабат гариза бирү датасына кадәр алты ай эчендә контрольдәге затның профилактик визит уздыру урынында булмавы яки аның профилактик визит уздырырга мөмкинлек бирмәгән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә;

3) гариза биргән көнгә кадәр бер ел эчендә элек бирелгән гариза буенча контроль орган тарафыннан профилактик визит үткәрелгәндә;

4) гаризада цензурасыз яки мыскыллаучы сүзләр, контроль органның вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булганда.

Профилактик визит уздырудан баш тарту турындагы карарга контрольдәге зат тарафыннан шикаять бирелергә мөмкин.

Контрольдәге зат гаризасын кире алырга яки профилактик визит уздырудан баш тартырга хокуклы, бу хакта контроль органына аны уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

33.3. Профилактик визит кысаларында контрольдәге затның ризалыгы белән инспектор пробалар (үрнәкләр) сайлап ала, инструменталь тикшерү, сынау үткәрә.

33.4. Контрольдәге затларга профилактик визит барышында бирелгән аңлатмалар һәм тәкъдимнәр рекомендация характерына ия.

33.5. Контрольдәге затларга профилактик визит барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирелә алмый.

33.6.Профилактик визит үткәргәндә контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы яисә мондый зыян (зарар) китерелүе ачыкланган очракта, инспектор контроль чаралар

үткәрү турында карар кабул итү өчен Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затына кичекмәстән мәгълүмат җибәрә.»;

4) 40 пунктта:

- 1, 3 пунктчаларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Федераль законның 60 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, Контроль органда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү турында яисә зыян (зарар) китерү куркынычы хакында белешмәләр булу;

3) контрольдәге конкрет затларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе (шул исәптән гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләренә карата);»;

- түбәндәге эчтәлектәге 5,6 пунктчалар өстәргә:

«5) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу яисә контроль объектының мондый параметрлардан тайпылу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау;

6) контрольдәге затның мәҗбүри профилактик визит уздырудан качарга тырышуы.»;

5) 51 пунктны түбәндәге эчтәлектәге бишенче абзац белән тулыландырырга:

«Инспекция визиты дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

6) 52 пунктны түбәндәге эчтәлектәге җиденче абзац белән тулыландырырга:

«Рейд күзәтүе дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

7) 56 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«56. Планнан тыш документар тикшерү, аны уздыруның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктларында каралган очракларыннан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килештереп үткәрелергә мөмкин.»;

8) 57 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән яки «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин»;

9) 59 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Планнан тыш күчмә тикшерү, аны уздыруның 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктларында, 3 өлешендә, 66 статьясындагы 12 һәм 12.1. өлешендә каралган очракларыннан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килештереп үткәрелергә мөмкин.»;

10) 61 пунктта

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча, Контроль төре турында Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, 248-ФЗ номерлы Федераль

законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.»;

- дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга.

11) 74 пунктны түбәндәге эчтәлектәге пункт г, д, е пунктчалары белән тулыландырырга:

«г) контроль объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарлар;

д) контрольдәге затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турында карарлар;

е) контрольдәге затларга яисә контроль объектларына карата 248 номерлы Федераль законда каралган профилактик һәм (яисә) контроль чаралары йомгаклары буенча контроль органнары тарафыннан кабул ителә торган башка карарлар»;

12) 82 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6, 7 пунктчалар белән тулыландырырга:

«6) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы 4 өлешенең 1-3 пунктларында каралган нигезләрдә шикаять бирелгән очракта, шикаять бирелә торган контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында контроль чараның яисә мәҗбүри профилактик визитның исәп номеры;

7) контроль төрләренең бердәм реестрында контроль объектының исәп номеры (контроль объектын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаять белдергәндә).»;

13) 89 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«89. Шикаять судка кадәрге шикаятьнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә Контроль орган тарафыннан каралырга тиеш.

Контрольдәге затның тикшерү объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.»

5. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/14 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8 номерлы Карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 28 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«28. Профилактик чаралар Контроль орган тарафыннан ел саен раслана торган закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау Программасы нигезендә гамәлгә ашырыла. Шулай ук күрсәтелгән Программада каралмаган профилактик чараларда үткәрелергә мөмкин.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Контроль орган профилактик чараларның түбәндәге төрләрен үткәрә: мәгълүмат бирү, консультация бирү, профилактик визит.

Мәҗбүри профилактик визит уздыру вакыты 10 эш көненнән артмаска тиеш һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле вакытка озайтылырга мөмкин.

Мәҗбүри профилактик визит тәмамланганнан соң мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт төзелә.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында инспектор кирәк булганда карап тикшерү, кирәкле документларны сорап алу, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза үткәрә.

Аны үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.

Контрольдәге зат яки аның вәкиле мәҗбүри профилактик визит актының эчтәлеге белән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 88 статьясында каралган тәртиптә таныша.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкин булмаган очракта, һәм (яки) контрольдәге затның аннан читләшүе очрагында инспектор тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 10 өлешендә каралган тәртиптә мәҗбүри профилактик визит үткәрү мөмкинлеге булмау турында акт төзелә.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә, әгәр мондый хокук бозулар мәҗбүри профилактик визит тәмамланганчы бетерелмәгән булса, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90.1 статьясында каралган тәртиптә контрольдәге затка бирелә.

2) 36 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Инспекция визиты дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

3) 40 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Рейд күзәтүе дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

4) 42 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Бер җитештерү объектында берничә контрольдәге зат эшчәнлек алып барган очракта, контрольдәге бер зат белән үзара хезмәттәшлек итү срогы, әгәр бу контроль төре турында Федераль законда каралган булса, бер эш көненнән артыграк булырга мөмкин.»;

5) 45 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«45. Документар тикшерү срогы 10 эш көненнән дә артмаска тиеш. Контроль орган тарафыннан контрольдәге затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру таләпләре җибәрелгән вакыттан алып, таләптә күрсәтелгән документларны контроль органына тапшырган вакытка кадәр, шулай ук контроль орган тарафыннан контрольдәге затка тапшырылган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында йә бу документлардагы белешмәләрнең контроль органындагы документлардагы һәм (яисә) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында контрольдәге затка контроль орган мәгълүматын җибәргән

вакыттан башлап, контрольдәге зат тарафыннан кирәкле язма аңлатмаларны контроль органына тапшырылган вакытка кадәр документар тикшерү үткәрү вакытын исәпләү туктатылып тора.»;

6) 46 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү дистанцион аралашу чараларын, шул исәптән видео-конференция элемтәсеннән, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

7) 54 пунктта «гамәлләрне кылырга» сүзләрен «үткәрелергә» дип үзгәртергә;

8) 56 пунктны көчен югалткан дип танырга;

9) 73 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«73. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган дип санаган контрольдәге затлар түбәндәгеләргә судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

а) контроль чаралар һәм мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү турында карарларга;

б) контроль чаралар актларына һәм мәҗбүри профилактик визитлар, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләргә;

в) контроль чаралар һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында контроль органныңы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына);

г) контроль объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарларга;

д) контрольдәге затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турында карарларга;

е) контрольдәге затларга яисә контроль объектларына карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90.1 статьясында каралган тәртиптә башка карарларга.»;

10) 81 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6, 7 пунктчалар белән тулыландырырга:

«6) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы 4 өлешенең 1-3 пунктларында каралган нигезләрдә шикаять бирелгән очракта, шикаять бирелә торган контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында контроль чараның яисә мәҗбүри профилактик визитның исәп номеры;

7) контроль төрләренең бердәм реестрында контроль объектының исәп номеры (контроль объектын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаять белдергәндә).»;

11) 88 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«88. Шикаять судка кадәрге шикаятьнең ярдәмче системасында теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә Контроль орган тарафыннан каралырга тиеш.

Контрольдәге затның тикшерү объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә соңга калмыйча карала.».

6. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ